Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын куллануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлану турында
ХӘБӘР ИТҮ

Әлеге белдерү белән җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлануы турында хәбәр итәбез: «16:15:050501:1440 кадастр номерлы җир кишәрлеген «дини файдалану»ның шартлы рөхсәт ителгән куллану төренә рөхсәт бирү турында» хокукый акты проекты буенча, Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 31.07.2026 елдагы №61/п карарына туры китереп

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге: фотоматериаллар

Проект буенча җәмәгать тыңлауларын уздыру тәртибе һәм сроклары: 06.08.2026 елдан 25.08.2026 елга кадәр.
Җәмәгать фикер алышулары Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законы, Югары Ослан муниципаль берәмлеге Уставы, муниципаль берәмлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендәге проект буенча җәмәгать фикер алышуларын, гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү турындагы Татарстан Республикасы Югары Ослан район Советы карары белән расланган Нигезләмә нигезендә үткәрелә.

Иҗтимагый фикер алышуда катнашучылар саны: кызыксынучы затлар.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышулар үткәрелә торган территория: Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы.

Проектның, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда карарга тиешле, күргәзмәсен ачу урыны һәм датасы: 06.08.2026 елдан мәгълүмати стендларда:
- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетына, адрес буенча: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт;
- Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитетына:
422570, Татарстан Республикасы, Югары Осланрайоны, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 54 йорт адресы буенча.

Проект экспозициясен үткәрү чорлары: 06.08.2026 елдан 25.08.2026 елга кадәр.

Экспозицияләргә керү мөмкинлеге булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат: дүш - җомга 09-00 сәг.тән 16-00 сәг.кә кадәр

Җәмәгать фикер алышуларында катнашучылар тарафыннан проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше
http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/: 06.08.2026 елдан 25.08.2026 елга кадәр булган, җәмгыять тавышларында карала торган проектның барлык чоры дәвамында, Югары Ослан районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ сәхифәсендә, «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» бүлегендә, проект экспозициясен үткәрү

вакытында, идентификация узган иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә - даими рәвештә

Татарстан Республикасы Югары Ослан районы муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелеше өлкәсендәге проектлар буенча җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру буенча гамәлдәге комиссиясенә (422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 нче йорт адресы буенча, тел: 8(84379) 2-16-59);

3) «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналына язу юлы белән.

Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә мондый проект урнаштырылачак һәм аңа мәгълүмати материаллар кулланып җәмәгать фикер алышулары уздырылачак мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районы сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Җәмәгать фикер алышуларында карала торган проект урнаштырылачак рәсми сайт турында һәм аңа информацион материаллар турында мәгълүмат: Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Әлеге хәбәрне бастырырга: 01.08.2026 елдан соңга калмыйча.

Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Башкарма комитеты җитәкчесе А.А. Әхмәтшин

Мәгълүмат стендларында иҗтимагый фикер алышулар башлану турында хәбәр итү урнаштыру турында Акт

Дата: 2026 елның 01 августы.

Әлеге акт Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 2026 елның 31 июлендәге 61/п номерлы карары нигезендә, кадастр номеры 16:15:050501:1440, мәйданы 5098 кв.м., Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авыл җирлеге, Югары Ослан авылы, Ясная урамы, җир участогы 1 адресы буенча урнашкан: «дини файдалану» рәвешендә шартлы рөхсәт ителгән кулланырга рөхсәт бирү проекты буенча белдерү урнаштыруны раслый.

түбәндәге мәгълүмат стендларында:

1) Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт адресы буенча архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге (106 каб.) — сәгать 10.00 нан;

2) Югары Ослан авыл җирлеге Башкарма комитеты: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 54 йорт адресы буенча — сәгать 11.00 дән

Актка кушымталар: фоторәсемнәр

Иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы
архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге баш белгече Нуруллина Ф.Х.